Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге Шәле авылының Урман, Яшьләр, Таулы, Тау асты, Тукай, Таҗиева, КамАЗ, Почта, Шәле тыкрыгы, Яңа урамнары гражданнары җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

19 октябрь, 2023 ел № 5

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге Шәле авылының Урман, Яшьләр, Таулы, Тау асты, Тукай, Таҗиева, КамАЗ, Почта, Шәле тыкрыгы, Яңа урамнарының 2023 елның 19 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 880 (сигез йөз сиксән).

- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 463 (дүрт йөз алтмыш өч).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 457 (дүрт йөз илле җиде).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 6 (алты).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2024 елда Шәле авыл җирлеге Шәле авылының Урман, Яшьләр, Таулы, Тау асты, Тукай, Таҗиева, КамАЗ, Почта, Шәле тыкрыгы, Яңа урамнарында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, сугыш һәм хәрби хәрәкәтләрендә катнашучыларны, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- юлларга ремонт» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Шәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Шәле авыл җирлеге башлыгы И.Р. Әхмәтҗанов